КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь

г.Казань

№ 1335

2022 елга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билетны һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билетны тулыландыру кыйммәтен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга түбәндәгеләрне билгеләргә:

транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билетны тулыландыру кыйммәтен 547 сум күләмендә;

балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билетны тулыландыру кыйммәтен 333 сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 апрель, 161 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең 7 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин